КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 03 март г.Казань № 200

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче; 2016 ел, 20 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 10 май, 268 нче; 2017 ел, 28 август, 604 нче; 2017 ел, 27 октябрь, 812 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче; 2019 ел, 5 август, 644 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1131 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче; 2021 ел, 12 июль, 567 нче; 2021 ел, 13 август, 713 нче;

2021 ел, 28 сентябрь, 918 нче, 2022 ел, 11 март, 214 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта:

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

җиденче абзацка «хезмәткәрләр вазыйфалары» сүзләреннән соң «, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер анасын яки атасын югалткан затларга» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацка «хезмәткәрләр вазыйфалары» сүзләреннән соң «, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер анасын яки атасын югалткан затларга» сүзләрен өстәргә;

тугызынчы абзацка «мәгариф программалары» сүзләреннән соң «, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер анасын яки атасын югалткан затларга» сүзләрен өстәргә;

унынчы абзацка «хезмәткәрләр вазыйфалары» сүзләреннән соң «, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер анасын яки атасын югалткан затларга» сүзләрен өстәргә;

уникенче абзацка «хезмәткәрләр вазыйфалары» сүзләреннән соң «, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер анасын яки атасын югалткан затларга» сүзләрен өстәргә;

3 бүлек үз көчен югалткан дип танырга;

6.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга ел саен бирелә торган пособие билгеләнә һәм түләнә:

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчаларына төп һөнәри белем бирү программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга һәм белем алу чорында ата-ананың икесен дә яисә бердәнбер ата-анасын югалткан, шул исәптән 23 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк булган затларга (алга таба - стипендия алучылар);

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчалары исәбеннән төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы ятим

балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында бер яисә ике ата-анасын югалткан затларга, күрсәтелгән белем бирү программалары буенча укулары тәмамланганчы.»;

түбәндәге эчтәлекле 6.2[1] пункт өстәргә:

«6.2[1]. Кием комплекты, аяк киеме һәм йомшак инвентарь сатып алуга еллык пособие, туклануга айлык пособие билгеләнә һәм түләнә:

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчаларына төп һөнәри белем бирү программалары буенча белем алуның көндезге формасында һәм (яисә) эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга һәм белем алу чорында ата-ананың икесен дә яисә бердәнбер ата-анасын югалткан, шул исәптән 23 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк булган затларга;

Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчалары исәбеннән төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында бер яисә ике ата-анасын югалткан затларга, күрсәтелгән белем бирү программалары буенча укулары тәмамланганчы.

Кием-салым комплекты, аяк киеме һәм йомшак инвентарь сатып алуга еллык пособие, тукланууга айлык пособие ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, карап тәрбияләгән өчен опекунга (попечительгә) акча түләнә торган тәрбиягә бала алган гаиләләргә билгеләнми һәм түләнми.»;

6.3 пунктка «хезмәткәрләр вазыйфалары» сүзләреннән соң «, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга һәм белем алу чорында ике ата-анасын яисә бердәнбер анасын яки атасын югалткан затларга» сүзләрен өстәргә;

6.4 пунктта «(алга таба - алучылар)» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.5 пунктта «алучылар» сүзен «6.1 - 6.4 пунктларында күрсәтелгән гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;

6.13 пунктта «алучы» сүзен «6.1 - 6.4 пунктларында күрсәтелгән граждан» сүзләренә алмаштырырга;

6.14 пунктта «алучы» сүзен «6.1 - 6.4 пунктларында күрсәтелгән граждан» сүзләренә алмаштырырга;

10.4 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин